ИСКЕЧӘ АЛДЫЙЛАР
Быел республикада финанс пирамидаларыннан зыян күрүчеләр 3 миллиард сум акчасын югалткан
> 2

ЭЛЕНМӘСЕН ЙОЗАК
Авылларлардагы балалар бакчалары ни сәбәпле ябыла?
> 3

ЭЗЕ «САТА»
Республикада кыргый хайваннарның санын алуга керештеләр
> 4

ДУСЛЫК ЯРЫШЫ
Казанда Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннары башланды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 10 (28977) | Сишәмбе | 24 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эшлекле сөйләшү

Татарстан горурлыгы. Республикадагы вазгыять. Лисичанскига ярдәм. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәү Кремлендә Илбашы Владимир Путин белән очрашты.

Республикадагы социаль-икътисадый вазгыятькә багышланган сөйләшүнең башында ук Россия Президенты Татарстанны мактады. «Татарстан, гадәттәгечә, күп еллар дәвамында төп юнәлешләр буенча рейтингларның югары баскычында урнашкан», – диде Илбашы. Шунда ук әңгәмәгә юнәлеш биреп: «Сезнең җитәкчелектәге зур хуҗалыкта да әле эшләргә кирәк булган яки тиешле дәрәҗәдә хәл ителмәгән мәсьәләләр булмый кала алмый. Бәлки, сөйләшүне шулардан башларгадыр?» – диде.

Рөстәм Миңнеханов игътибарны көнүзәк мәсьәләгә юнәлтте.

– Махсус хәрби операциягә ярдәм чаралары турында әйтәсем килә. Бу барыбыз өчен дә бик мөһим. Әлеге максаттан, шул исәптән республика шефлыкка алган Лисичанск шәһәренә дә 2,5 миллиард сумга якын акча бүлеп бирдек. Кызганыч, Лисичанскида бар көчебезгә эшли алмыйбыз әле. Безнең ике батальон – «Алга» һәм «Тимер» хәрби операция зонасында. Донбасска республикадан 2 мең тонна гуманитар ярдәм озаттык. Аның шактый өлеше Лисичанскига китте. Шәһәрдә нәрсәләр эшләргә кирәк икәнен яхшы беләбез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты сөйләгәннәрне куәтләпме, Владимир Путин «алга» сүзен русчага тәрҗемә итеп тә әйтте.

Икътисадый вазгыять турында хисап тотканда, Рөстәм Миңнеханов тармактагы төп саннарга тукталды. Былтыр төбәктәге тулай продукт күләме 3,7 триллион сумнан артып киткән. Татарстан 1,4 триллион сум салым җыйган. Күрсәткечләрне алга таба да саклап калырга вәгъдә итте Рөстәм Миңнеханов. Узган ел төп капиталга инвестицияләр күләме 774 миллиард доллар тәшкил иткән. «Әлеге күрсәткеч үстеме?» – дип тә кызыксынды Илбашы һәм уңай җавап ишетте.

Владимир Путин республикада эшкәртү сәнәгате тармагы күрсәткечләренең артуына да игътибар итте. Былтыр чимал булмаган экспорт күләме ике тапкыр диярлек арткан.

– Әйе, дөрес. Чөнки без моңарчы нефтьне сата идек. Ә хәзер нефть химиясе, эшкәртүдән соң барлыкка килгән продукция сатабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Без 24 миллион тонна «кара алтын» эшкәртәбез. Нефтьне эшкәртү белән шөгыльләнүче ике зур комплексыбыз бар – «ТАНЕКО» һәм «ТАИФ-НК». Хәзер безгә «СИБУР» килде. Алар белән нәтиҗәле эшлибез.

Татарстан Президенты ачыклык та кертте: эре инвестор «ТАИФ»ның кайбер заводларын сатып алган. Татарстан холдингы «СИБУР»ның акционеры булып исәпләнә. Республикада ашлама заводы да уңышлы эшли. Инвестор Роман Троценко әлеге сәнәгатьне тагын да үстерүне күздә тота. «Аммиакмы?» – дип ачыклык кертте Владимир Путин. Аңа җавап итеп: «Әйе. 1 миллион тоннадан артык аммиак җитештерәләр инде, әлеге күрсәткечне 3 миллион тоннага җиткерергә телиләр», – диде Рөстәм Миңнеханов. Республика предприятиеләре экология проектлары турында да онытмый.

– Соңгы 20 елда төбәктәге тулай продукт күләме 3 тапкыр диярлек артты, ә һавага чыгарылган зарарлы газлар – 20, ташландык сулар 60 процентка кимеде. Бу юнәлештә Казанда зур эш алып барыла. Шул исәптән «Ростех» белән бергә чүп эшкәртү комплексы төзибез, – диде республика башлыгы.

kremlin.ru

ХАЛЫК КӨТӘ

Машина төзелеше тармагында да уңышлар шактый: былтыр КАМАЗда 43 меңгә якын йөк машинасы җитештергәннәр. «Форд» китте, ә аның урынына «Соллерс» коммерцияле җиңел йөк машиналары чыгара башлады. Казан авиация заводы 10 «Ту-124» очкычын җитештерүгә заказ алган. «Татарстанның горурлыгы», – диде Владимир Путин әлеге очкыч турында.

Рөстәм Миңнеханов IT технологияләр тармагындагы проектлар турында да телгә алды. Әле күптән түгел Казанда яңа IT парк ачылуын әйтте ул.

– Укытучыларга – 24 мең ноутбук. Мәктәпләргә җиһазларны бер тапкыр тараттык инде, монысы – икенчесе. Бөтен укытучыларны ноутбук белән тәэмин итү өчен 45 мең җиһаз кирәк булачак. Иннополиска бәйле проектлар бар. Яңа ICL заводы төзелә. «Алабуга» махсус икътисадый зонасы уңышлы эшли. Әлеге мәйданнар тулаем сәнәгать продукциясенең 10 процентын җитештерә. Биредә 2,1 мең резидент эшли. Барлык объектларның уртак кереме 515 миллиард сумга якын тәшкил итә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесе әйтүенчә, Татарстанда 44 программа гамәлдә. Аларның һәркайсы буенча эш алып барыла. Мәктәпләр төзелә, сәламәтлек саклау оешмалары төзекләндерелә, республиканың һәр районын диярлек футбол кырлары белән тәэмин итәргә тырышалар. Юлларга чират җиткәч, Рөстәм Миңнехановны Владимир Путин бүлдереп: «Республиканың авырткан җире, дөресме?» – диде. «Бернинди кыенлык та юк», – дигән җавап ишеткәч, каршы килеп, халыкның кәефеннән чыгып чамалавын әйтте. Димәк, тагын да тырышыбрак эшләргә кирәк, дигән фикергә килделәр.

Рөстәм Миңнеханов «М12» автомагистрале өчен зур рәхмәт әйтте. Зур төзелеш кысасында, республикада 100 миллиард сумлык юл салганнар инде. Моннан тыш, Түбән Кама һәм Чаллыны уратып юл төзелә. Идел һәм Чулман аша күпер салалар.

– Бу кадәр зур төзелешләр совет чорында да булмаган хәтта. Юллар, күперләр – барысы да план буенча бара. Марат Хөснуллин эшне каты контрольдә тота. Шуңа күрә халык та көтә: ник бездә вак таш җәелгән дә, башкалар асфальт юлдан йөри, дип ризасызлык белдерәләр, – дип алда әйтелгәнгә кире кайтты Рөстәм Миңнеханов.

Сөйләшү ахырында Рөстәм Миңнеханов Владимир Путин кушуы буенча үзе җитәкләгән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме эше турында да җиткерде. Эшче төркемгә Россиядән 36 һәм чит илләрдән 34 вәкил керә. Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгары дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 еллыкка багышланган бәйрәм чараларын үткәрүдә ярдәм итүе өчен дә рәхмәтен белдерде.

– Сез «KazanSummit»ны федераль дәрәҗәгә күтәрү бурычын куйдыгыз. Узган ел Казан Ислам хезмәттәшлеге илләренең башкаласы булды. Чарада 70тән артык илдән вәкил катнашты. Һәм, әлбәттә, ЮНЕСКО буенча эшчәнлек зур әһәмияткә ия. Минтимер Шәймиев бу юнәлештә зур эш башкара, – диде ул.

– Яхшы, – дип әңгәмәне җөпләп куйды Владимир Путин.

Ярдәм юлга чыкты

Татарстаннан Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәренә мич, балта, җылы киемнәр, азык-төлектән торган 115 тонна гуманитар ярдәм озатылды. Аны биредә яшәүче җирле халыкка һәм мобилизациягә эләккән Татарстан егетләренә тапшырачаклар. Бу эшне оештырган «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте координаторы Тимур Сафин сүзләренә караганда, быел республикадан Лисичанскига озатылган иң беренче һәм зур гуманитар йөк бу. Анда кышкы чорда кирәк булган бар нәрсә тупланган. Моннан тыш гуманитар йөк составында шәһәрдәге җимерекләрне төзәтү өчен кирәкле төзелеш материаллары да бар. Кайбыч һәм Кама Тамагы районнары бу максаттан 20 тонналык 400 капчык цемент әзерләгән. Якын арада хәрәкәт активистлары хәрби госпитальләр өчен кирәк-яраклар да җыя башламакчы.

«Без моңарчы ике-өч атнага бер тапкыр гуманитар йөк озата килдек. Шушы ешлыкны саклап каласы, мөмкинлек булса, гуманитар ярдәмне тагын да ешрак озатасы иде. Ник дигәндә, мобилизациягә эләккән егетләребез үз бурычларын үти, гуманитар ярдәмгә мохтаҗлык зур. Шуңа күрә без аларга кулыбыздан килгән кадәр булышырга тиеш», – ди Тимур Сафин.

Хатын-кызларга азрак түлиләр

Россиядә хатын-кызларның хезмәт хакы, элеккечә үк, ир-атларныкыннан кимрәк. Эш хакындагы аерма 28 процентка җитә. Россия хезмәт һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары Ольга Баталина искәртеп үткәнчә, илдә гүзәл затларга рөхсәт ителмәгән һөнәрләр исемлеге 456дан 100гә калган. Күрелгән барлык чараларга карамастан, алар карьера баскычыннан авыррак күтәрелә. Гәрчә осталыклары ягыннан ир-атлардан калышмаса да.

Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе Нина Останина сүзләренә караганда, Россиядә эшсезләрнең яртысы диярлек (49,4%) – нәфис затлар. Алар эшкә урнашу өчен ирләргә караганда күбрәк вакыт сарыф итә (7 ай чамасы). Шул ук вакытта мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрнең 82,4 проценты, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәләрендә эшләүчеләрнең 79,8 проценты – туташ-ханымнар.

Эзтабарлар һаман эзли

Узган ел Татарстан эзтабарлары Бөек Ватан сугышы чорында һәлак булган 326 солдатның калдыкларын тапкан. 11енең шәхесен ачыклый алганнар.

«Отечество» берләшмәсенең яшьләр иҗтимагый оешмасы советы рәисе Александр Коноплев әйтүенчә, 2022 елда барлыгы 30дан артыграк эзләү экспедициясе оештырылган. Аларда 600дән артыграк эзтабар катнашкан. Солдатларның кем икәнлеген белергә медальоннары яки инициаллары язылган шәхси әйберләре ярдәм итә. Ә инде төгәлрәк белгеләргә кирәк булса, эзтабарлар калдыкларның ДНКсын һәлак булганнарның туганнары дип фаразланган кешеләрнеке белән чагыштыра.

Татарстаннан апрель аенда тагын бер эзләү экспедициясе планлаштырыла.

Икътисад

Әлегә иртәрәк

Кредит буенча айлык түләүне ничек киметеп була? Эшне нидән башларга? Соңгы арада кредитны рефинанслау, ягъни аның процент ставкасын төшереп, айлык түләүне аз булса да киметүгә бәйле шундый сорауларны еш ишетергә туры килә. Әмма белгечләр ашыкмаска киңәш итә.

Риелтор Дамир Сафиуллин әйтүенчә, бүген кредитны рефинанслаудан мәгънә юк. Ник дигәндә, әлегә ставкалар бик югары.

– Кредитны ставкалар 8–9 процентка кадәр төшкән очракта гына рефинанслау отышлы. Дөрес, бик теләгән кеше моны банкка өстәмә акча түләп эшли ала. Әйтик, бүген ставкалар 11,9 проценттан да ким түгел. Әмма кеше кредит суммасының 9,9 проценты күләмендә өстәмә акча түләсә, банк аның кредит ставкасын 8,9 процентка кадәр төшерә ала, – ди риелтор.

Кредитны рефинанслау тагын кайсы очракта отышлы? Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, әлеге программадан файдаланганда, кеше ким дигәндә 100 мең сум акчаны янга калдырырга тиеш. Шулай булмаса, бер кредитны икенчесенә алмаштырудан мәгънә юк. Кредит түләү вакыты 5 елдан да азрак калып барган кешегә дә кредитны рефинанслаудан файда юк. Әлеге программадан файдаланганда, торак сатып алганда тотылган акчаның 13 процентын кире кайтару мөмкинлеге дә саклана. «Ә менә берничә кредитны берләштереп, яңа кредит алганда алай эшләп булмаячак», – ди белгеч.

Кредитын рефинанслаган кеше аның айлык түләвен дә, түләү вакытын да киметә ала. Закон нигезендә, ипотека кредитыннан тыш куллану кредитын да рефинанслап була. Берничә кредиты булган кеше дә, аларны каплау өчен, түбәнрәк процентлы яңа кредит алырга мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Ай саен кредит түләп яшәгән гаилә бюджетына да азмы-күпме файда була. Дөрес, рефинанслаганда иң беренче тапкыр кредит алган чактагы кебек үк барлык документларны яңадан җыясы, гомерне яңадан иминиятләштертәсе, шактый гына өстәмә акча чыгарасы да булачак. Кеше шушы мәшәкатьләргә дә әзер торырга тиеш, – ди Дамир Сафиуллин.

Ике көннең берендә халыкны алдау очраклары турында ишетеп торганда, арабызда кредитны рефинанслау эшенә дә шикләнеп караучылар шактый. Әмма белгечләр фикеренчә, банклардан алданырмын дип курку кирәкми. Алар барысы да бер үк дәрәҗәдә диярлек ышанычлы, дигән фикердә Дамир Сафиуллин.

– Алар арасыннан сайлаганда түбәнрәк процент ставкасы тәкъдим иткән, нинди дер өстәмә хезмәтләр такмаганына өстенлек бирергә кирәк. Аерма бары шунда гына. Рефинанслауны милек агентлыклары, кредит брокерлары аша да ясарга мөмкин. Әмма хезмәт өчен алдан акча сораган оешмалардан ерак торырга киңәш итәр идем. Алар эшне ахыргача алып барып җиткерәчәк, дип беркем ышандыра алмый. Мондый эш бары тик килешү төзеп кенә башкарылырга тиеш.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Олег МАТЫЦИН, Россиянең спорт министры:

Без халыкара чикләүләргә каршы көрәш шартларында яшибез. Алар күпмедер дәрәҗәдә көчебезне чамаларга ярдәм итә. Татарстан чикләүләргә ничек җавап бирергә кирәклеген күрсәтә. Әмма без аңларга тиеш: спорт ул автоном тармак түгел. Спортчыларыбыз бар җирдә чыгыш ясый, аларны нәрсәдән дә булса мәхрүм итү бик җиңел. 2023 ел уйлаган проектларыбыз аша көчебезне күрсәтергә мөмкинлек бирер дип ышанам.

(Татарстан Спорт министрлыгы коллегиясе утырышындагы чыгышыннан)

ТАТАРСТАНДА – ТЕРЛЕКЧЕЛЕК

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган ел нәтиҗәләре буенча Кукмара, Мамадыш, Балтач, Түбән Кама, Саба һәм Азнакай районнарында мөгезле эре терлек саны арткан. Чүпрәле, Чистай, Әлки, Буа һәм Яшел Үзәндә исә кимегән.



Мөгезле эре терлек	638 мең
Дуңгыз	439,6 мең
Ат	18,4 мең
Сарык	49 мең
Кәҗә	4 мең
Кош-корт	15 млн

Рәхәт суык

Татарстанда антициклон йогынтысында җиңелчә генә суык һава урнашты. Пәнҗешәмбегә бераз җылыта.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 25 мартта – көндез –5…–10, төнлә –12…–17, урыны белән –22 градуска кадәр салкын көтелә. Явым-төшем булмаячак. Пәнҗешәмбе – 26 гыйнварда – температура бераз күтәреләчәк. Көндез термометр –2…–7, төнлә –8…–13, урыны белән –17 градус күрсәтәчәк.

Башлангыч фаразлар буенча, җомга һәм шимбә – 27–28 гыйнварда – республикада урыны белән аз гына кар явып үтәчәк. Җиңелчә салкын һава сакланып кала: көндез термометрның терекөмеш баганасы –5…–10, төнлә –11…–16 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«РАМШТАЙН» НӘРСӘ ВӘГЪДӘ ИТӘ?

Дөньяның төп вакыйгалары елга якын Россия – Украина конфликты тирәсендә бөтерелә. Каршылык Көнбатыш – Көнчыгыш конфликтына үсә һәм максатлары игълан ителгәннән күпкә аерыла. Вашингтонның – үз планнары, Брюссельның – үз мәнфәгатьләре, Лондон омтылышлары, Кытай һәм Һиндстан максатлары Мәскәү ниятләре белән бәрелешә.

Конфликтта күп илләрнең хәрби-сәнәгать комплекслары мәнфәгатьләре төенләнгән. Асылда дөнья базарын бүлешү бара. Кытай һәм Һиндстан арзанлы углеводородлар сыйфатында беренче дивидендлар алып өлгерде. Аларга Россия базары киң ачылды. 2022 елда газ экспорты буенча Россия дөнья лидеры иде, 2023тә лидер АКШ булачак. Конфликтның артында безгә күренми торган тагын бик күп җепләр сузылган һәм шуңа күрә аның дәвамлы булуын теләгән көчләр бихисап.

Үткән атнада Германиянең «Рамштайн» авиабазасында Россиягә каршы коалиция Украинага хәрби ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен тикшергән яңа очрашу үткәрде. Игътибар итик: коалиция НАТО блогыннан күпкә киңрәк. Киев позициясен яклаучылар арасында Азия һәм Африка илләре бар һәм илләр саны иллегә якынлаша. «Рамштайн» алдыннан Көнбатыш тагын бер уңышка иреште: Россия аркадашы дип саналган илләр – Иран һәм Сербия Кырымны һәм Донбассны Украинаныкы дип белдерделәр.

Киевка хәрби ярдәм күрсәтү буенча киңәшмәләр кайда гына уздырылса да (хәтта онлайн форматта үткәрелсә дә), «Рамштайн» дип атала, чөнки сүзнең мәгънәсе «таш таран» дигән мәгънә бирә. Соңгы очрашуда украиннарны калканлы техника белән тәэмин итү каралды. Калканлы пехота машиналарын тапшыру бәхәс тудырмады. Американнар 58 (59 дип тә әйтәләр) M2 Bradley машинасын бирергә вәгъдә иткәннәр иде инде. Канада шулай ук 200 БМП тапшырырга тели, шведлар да күп техника китерергә җыена. Үзйөрешле артиллерия җайланмалары да бәхәс тудырмый. Нигездә Германиядә җитештерелгән һәм уннан артык илгә сатылган Leopard һәм Leopard 2 танклары тирәсендә сүз көрәштерделәр. «Российская газета» мәгълүматларына караганда, Киевка инде 400дән артык совет танкы тапшырылган. Болар гына канәгатьләндерми, чөнки Көнбатышның дүртенче буын танклары технологик яктан күпкә яхшырак һәм хәрби конфликтта өстенлек вәгъдә итә. Немец танклары мәсьәләсе хәл ителеп бетмәде. Польша һәм Словакия үзләрендәге «Леопард»ларны бирергә әзер. Украина хәрбиләре инде аларда өйрәнү үтә. Бирелгән техника да, сан ягыннан күп булмаса да, технологик характеристикалары белән куркыныч тудыра. Әйтик, шведларның «Archer» үзйөрешле гаубицалары дөньяда иң куәтле булулары һәм 30 секунд эчендә утны башка юнәлешкә күчерә алулары белән аерылып тора. Киләсе «Рамштайн» авиация һәм ракеталар мәсьәләсенә багышланачак. F-16 очкычларын Украинага бирергә әзер торган ил бар инде. Конфликт Россия өчен дәһшәтлерәк яссылыкка күчә һәм Мәскәүдә, билгеле, бу зур ризасызлык тудыра. Дума спикеры Володин атом коралы белән Көнбатышка янады инде.

Россиядә

ЭШНЕҢ БЕТӘСЕ ЮК

Үткән пәнҗешәмбедә Дәүләт Думасында эшләүче пенсионерлар акчасы тирәсендә кылычлар чыңлады. 2016 елда федераль хөкүмәт инициативасы белән «кем эшли, шул аз пенсия ала» дигән кагыйдә гамәлгә кертелде. Инфляциялe икътисад шартларында кесәгә ярыйсы ук суга торган нәрсәгә әйләнде ул.

Шул еллар эчендә эшләмәгән пенсионерлар акчасы 74 процентка артып өлгергән инде. Эшләүче өлкәннәрнең уртача югалтулары 8878 сум тирәсе дип исәпліләр. Бер елга – 106 мең 536 сум. Белгечләр югалтуларны тагын да зуррак дип бәяли. Балларны киметеп исәпләү нәтиҗәсендә тагын айга 5 мең сум акча югала, диләр. Соңгысы буенча бәхәсләшү кыен, әмма индексациясез калу сәбәпле турыдан-туры югалтулар гына да 6–7 елга миллион сумга таба якынлашып килә инде. Пенсионерларның байтагы югалтулардан качуның юлларын тапты. 6 миллионнан артык кеше теркәлми эшли башлаган. 2016 елда рәсми рәвештә эшләүче пенсионерлар саны 15,3 миллион булса, хәзер 9 миллион тирәсе. Рәсми рәвештә теркәлеп эшләүчеләр дә җай табалар: бер айга эштән китеп торып, картлык акчаларын арттыруга ирешәләр һәм яңадан эшкә урнашалар. Йөз мең сумнан арткан югалту белән бер айлык хезмәт хакын чагыштырып булмый бит инде. Бу – законлы ысул, беркем дә гаепли алмый.

Федераль хөкүмәтнең индексация мәсьәләсендә җан тартышуы аңлашылмый, чөнки, бердән, күпчелек пенсионерларның акчасы, эшләсә дә, индексацияләнә, икенчедән, индексация ясамау икътисад өчен зыянлы. Рәсми рәвештә эштән китеп, күләгәдә эшәләүчеләр салым да түләми, Пенсия фондына алардан взнос та керми. Бюджет байтак акча югалта. Индексация рәвешендә пенсионер кесәсенә кергән акча товар әйләнешенә кушылып, шунда ук бюджетка әйләнеп кайта. Монысы да зур нәрсә аның, чөнки кибеттән товар алганда, салым түлибез. Бензин бәясендә, мәсәлән, салымнар 69 процентка җитә, диләр.

Дәүләт Думасы депутаты Оксана Дмитриева әйтүенчә, индексация өчен 420 миллиард сум акча кирәк, ә күләгәгә качкан пенсионерлар теркәлеп эшләсә, 1,5 триллион сум салым түләрләр иде. Хисап палатасы ел башына шул югалтулар турында исәпләүләр кертергә тиеш булса да, бу никтер эшләнмәгән.

Пәнҗешәмбе көнне индексациягә кагылышлы биш канун проекты Дәүләт Думасы тарафыннан кире кагылды. Конституциягә үзгәрешләр керткәндә, индексация мәҗбүрилеге махсус статья итеп тә язылган иде югыйсә. Владимир Путинның да хөкүмәткә мәсьәләне хәл итәргә әмер бирүенә байтак вакытлар үтте. Финанс министрлыгы казнада акча юк дигән сәбәп күрсәтә, эшләүчеләрнең хезмәт хакы индексацияләнә дигән сылтау таба. Пенсионерлар мәнфәгатен яклаучылар көрәшне дәвам итәргә вәгъдә бирә.

АВЫЗ ПЕШКӘЧ, СОҢ ИНДЕ

3 миллиард сум! Былтыр республикада финанс пирамидаларыннан зыян күрүчеләр әнә шулкадәр акчасын югалткан. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясе утырышында республикада теркәлгән җинаять очраклары, аларны ачыклау һәм халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү турында сөйләделәр. Чынбарлык – саннарда. Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

tatarstan.ru

Министр Артем Хохорин сүзләренә караганда, кадрлар, техник һәм профилактик мәсьәләләрне хәл итү нәтиҗәсендә вазгыятьне кулдан ычкындырмаганнар.

– Теркәлгән җинаятьләр саны тотрыклы булып кала. Шул ук вакытта авыр һәм аеруча авыр төрләре саны кимеп, соңгы 15 ел эчендә иң түбән күрсәткечкә җитте, – дип билгеләп үтте министр.

Былтыр республикада 52 меңнән артык җинаять очрагы теркәлгән. Алдагы елларда килеп чыкканнары игътибардан читтә калмый. Халык арасында шактый шау-шу тудырган җинаятьләр дә фаш ителде, дип сөйләделәр коллегиядә.

Бүгенгеләренә килгәндә, хокук саклаучылар әйтүенчә, соңгы биш елда Татарстанда IT технологияләр ярдәмендә кылынган җинаятьләрне тикшерүләр саны биш тапкыр арткан. Былтыр, мәсәлән, шундый 18 меңгә якын очрак теркәлгән. Аларның күп өлеше, тәгаен әйтсәк, 9 меңнән артыгы мошенникларга туры килә. Тагын 4 меңгә якын очракта банк картасыннан акча урлаганнар. Ә 1600 очракта интернет аша наркотик матдәләр белән сату иткәннәр. Узган ел читтән торып кылган караклык очраклары аркасында гына да 2 миллиард 895 миллион сумлык (!) зыян килгән. Шуңа күрә хокук саклаучылар тагын бер кат кисәтә: былтыр алдауның инде искергән булып тоелган ысулларын файдаланып, халыкны кабат төп башына утыртырга теләүчеләр саны арткан. Бигрәк тә пенсионерларны алдыйлар, ди. «Мәсәлән, туганыгыз юл һәлакәтенә эләкте, ашыгыч рәвештә акча кирәк, дип еш шалтыраталар. Мондый коткыга бирелмәгез», – дип кисәттеләр утырышта. Узган ел әнә шундый кырыгалдарлар аркасында халык 80 миллион сум акчасын югалткан. Хәер, зыян күләме акча белән генә дә исәпләнми. Узган елның ноябрендә Казанда яшәүче 74 яшьлек әбигә: «Оныгыгыз юл һәлакәтенә эләкте», – дип шалтыратканнар һәм мошенникларга 200 мең сум акча күчерергә үгетләгәннәр. Соңрак оныкка берни дә булмаганы ачыклана. Бу хәлне күтәрә алмаган әбине исә үз-үзенә кул салган килеш табалар. Рульдә йөрүчеләр арасында «юлдаш табып бирәм» дип алдау очраклары да арткан. Еш кына кырыгалдарларның, гомумән дә, илдән читтә урнашкан махсус оешмалардан шалтыратуы ачыклана.

Күпме генә сөйләсәләр дә, финанс пирамидалары тозагына эләгүчеләр саны кимеми. Соңгы мәгълүматларга караганда, хокук саклаучыларның өстәлендә халыкка байлык вәгъдә итүче оешмаларга бәйле 12 эш ята. Аерым алганда, «РуссИнвестГрупп», «Креатив-Инвест» кебек финанс пирамидалары турында билгеле. Зыян күрүчеләр исемлегендә 13 меңнән артык кеше исәпләнә. Тиз арада баеп китәргә теләүчеләр 3 миллиард сумнан артык акчасын югалткан.

Иң куркыныч саннар – узган ел республикада террорчылыкка бәйле 26 җинаять очрагы ачыкланган. Моңа өстәп, экстремистик юнәлештәге 22 очрак билгеле булган. Коллегиядә бу афәткә каршы көрәш чаралары турында да әйттеләр. Аерым алганда, интернетта «колумбайн», ягъни уку йортларында ут ачуга өндәүгә бәйле мәгълүматларны даими карап-тикшереп торалар. Былтыр шикле дип табылган 27 чыганакны япканнар. Әлеге мәгълүматны таратуда катнашкан 2 кеше тоткарланган. Татарстанлылар да уяулыкны югалтмый. Ел дәвамында хокук саклаучыларга төрле чыганаклардан «колумбайн» идеологиясен таратуга бәйле 62 хәбәр килеп ирешкән. Нәтиҗәдә әлеге эшкә катнашы булган 11 кешене психиатрия клиникасына тикшерелергә һәм дәваланырга җибәргәннәр.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, узган ел илебез, республика, аерым алганда, Эчке эшләр министрлыгы өчен җиңел булмады.

– Моңа да карамастан, гомумән алганда, хокук тәртибен тәэмин итү бурычлары үтәлгән, оператив хезмәт эшчәнлегенең барлык төп юнәлешләре буенча уңай нәтиҗәләргә ирешелгән. Икътисадый һәм салым җинаятьләрен ачуда, оешкан җинаятьчел төркемнәргә каршы көрәштә, наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәштә мөһим уңышлар бар. Бу күрсәткечләргә министрлыкның барлык хезмәтләренең җитди эше, шулай ук Эчке эшләр министрлыгының башка хокук саклау структуралары, ведомстволар һәм хакимият органнары белән гамәлләрен нәтиҗәле җайга салу хисабына ирешелде, – диде Президент.

Алда торган бурычлар турында сөйләгәндә, Рөстәм Миңнеханов наркотикларга каршы көрәш мәсьәләсенә, чит илдән килгән кешеләргә игътибарлы булырга кушты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сан

Татарстанда былтыр ришвәт алуга бәйле 589 очрак ачыкланган. Намуссыз кешеләрнең кесәсенә 102 миллион 589 мең сум акча кергән. Ришвәтнең уртача күләме – 174 мең сум.

Күзәтеп торачаклар

Халыкның прокурорларга ышанычы зур. Бу хакта Татарстан Прокуратурасының еллык коллегиясе утырышында әйттеләр. Бергәләп эшләгәндә алда торган бурычларны хәл итүдә шик юк.

Татарстан Прокуроры Илдус Нәфыйков сүзләренә караганда, узган ел тармак вәкилләренә моңарчы күрелмәгән шартларда эшләргә туры килгән.

– Былтыр гражданнарның төп хокукларын һәм ирекләрен, җәмгыять һәм дәүләтнең законлы мәнфәгатьләрен яклауга аерым игътибар бирелде. Җәмгыять бездән көнүзәк проблемаларны хәл итүдә яклау һәм ярдәм көтә. Без алга куелган барлык дәүләт бурычларын хәл итәргә тиеш, – диде Прокурор.

Узган елда республика прокуратурасы органнарына 100 меңгә якын мөрәҗәгать килгән. Аларны карап тикшергәндә 12 меңнән артык хокук бозу очрагы ачыкланган. Халыкның прокурорларга ышанычының югары дәрәҗәдә булуын Рөстәм Миңнеханов та билгеләп үтте. Аның әйтүенчә, махсус хәрби операция үткәрелү сәбәпле, сыену корылмаларын тәртиптә тоту һәм кулланугa бәйле законнарның үтәлешенә бәйле максатчан эшчәнлекне дәвам итәргә кирәк. Хәзерге вакытта республикада шундый 1091 корылма исәпләнә, аларның 673е файдалануга әзер.

– Прокуратура органнарына әлеге мәсьәләне контрольдә тотарга кирәк, – дип басым ясап әйтте Президент.

Рөстәм Миңнеханов илкүләм проектларның үтәлешен җентекләп күзәтеп барырга, инвалид балаларның хокукларын яклауга да аерым игътибар бирергә киңәш итте.

Башка караш

Парламенттагы КПРФ фракциясендә нибары алты депутат, шуңа күрә аларның һәрберсе үз йөген төптән җигелеп тартырга тиеш. Алар эшләгән булып кылана алмый, һәрберсенең ни кылганы (яки кылмаганы) кеше күз алдында. Ике кулына бер эш булган депутат та берәү генә, ул – фракция җитәкчесе Хафиз Миргалимов.

Калганнары – төрле һөнәр ияләре, ягъни депутатлыктан башка үз эшләре дә муеннан. Шуңа күрә иптәш Миргалимов: «Их, тагын бер ирекле депутат булса иде!» – дип, җае чыккан саен әйтә килә.

Шунысын әйтик: зурлап алганда, алар дәүләт сәясәтенә әллә ни йогынты ясый алмыйлар, әмма, Хафиз иптәш әйтмешли, «оппозициядәге бердәнбер партия» буларак, күп нәрсәгә каршы килеп, хакимиятне һәм хакимияттәге партияне кымтырыклап торалар.

Узган җомгада үткәрелгән матбугат конференциясендә дә «без риза түгел», «без каршы» дигән сүзләр мулдан яңгырады. Бер уйлаганда, аларның җитешсезлекләрне, тискәре күренешләрне тәнкыйтьләве кесәдән йодрык күрсәтү кебек тоелып китә. Әмма хакимияткә сүзләре үтү дә хак, аларның мөрәҗәгатенә Президент та колак сала, парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да, Премьер-министр Алексей Песошин да хәерхаһлы мөнәсәбәттә. Алар меңләгән кешенең коммунист депутатларга өмет баглавын аңлый.

Мәсәлән, соңгы вакытларда депутатларга өлкән яшьтәге бер ханым мөрәҗәгать иткән. Аны, күчемсез милке бар дип, җәмәгать транспортында бушлай йөрү хокукыннан мәхрүм иткән булганнар. Ә «күчемсез милек» дигәннәре ярым җимерек сарайдагы иске баз икән. Социаль яклау органнары аны «өстәмә табыш китерә торган» объект дип бәяләп, реестрга керткәннәр. Шуның ише «вак-төяк» мөрәҗәгатьләр бихисап керә КПРФ депутатларына һәм алар өчен мәсьәләнең зуры-кечкенәсе юк.

Матбугат конференциясе КПРФ фракциясенең узган елгы эшчәнлегенә багышланган иде. Депутатлар барлыгы 313 мөрәҗәгать карап, хакимият органнарына җибәргәннәр. Аларның тәкъдимнәре, нигездә, үтәлә бара. Фракция җитәкчесенең Президент һәм Хөкүмәт тарафына әледән-әле рәхмәт сүзләре юллавы бераз төчелек кебек тоелган иде, әмма моны кемгәдер ярарга тырышу, яхшы атлы булып кылану түгел, ә депутатлар күтәргән иң әһәмиятле мәсьәләләргә җитәкчелекнең колак салуы, хакимиятнең барлык тармаклары, парламенттагы барлык партияләрнең бердәм эшләве дип кабул итсәк, дөрес булыр,

Әлбәттә, КПРФ күп нәрсәдән риза-бәхил түгел: Президент атамасын үзгәртүгә, тарифлар сәясәтенә, пенсия һәм хезмәт хакының түбән булуына да каршы. Хафиз иптәш: «Илдә байлык, акча бар, сәяси ихтыяр гына юк», – ди.

Сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендәге җитешсезлекләрне дә тәнкыйтьлиләр алар, шул хакта «түгәрәк өстәл» уздыруга да әзерләнәләр. КПРФ Бердәм дәүләт имтиханын, гомумән, санламый, андый нәрсә бүтән бер илдә дә юк, дип бара.

Без фракциянең узган ел ничә утырыш уздырганын, нинди изге гамәлләр кылуын санап тормыйбыз. Әмма хакыйкатьнең бары тик бәхәстә тууын тагын бер кат искә төшерәсе килә. Дөрес, бездә алга киткән кайбер илләрдәге кебек чын, көчле оппозиция юк, әмма каршылык хәрәкәте бар. Ә үсеп, алга китүнең төп шарты – каршылык.

Февральдә КПРФ оешуга 30 ел тула. Фракция әлеге юбилейны зурлап билгеләп үтәргә җыена. Еллар узсын ул, туктап кына калмасыннар, җәмгыятьтә төрле фикер дә яшәсен.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы 26 гыйнвар көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 26 гыйнварда 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

ЦИФРЛЫ АВЫЛ

Яңалык

Һәр бинасына куар-кодлар, авылда күзәтү камералары урнаштырылган җирлек турында ишеткәнегез бар идеме? Узган ел «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсында җиңү яулаган Кырым-Сарай авылында менә шулай замана белән бергә атлыйлар.

Кая килеп эләккәнеңне Кырым-Сарайга җиткәндә үк аңлыйсың.

Цифрлаштыру Баулы районының Кырым-Сарай авыл җирлегенә 13,5 миллион сум акча китергән. Башлык Дамир Шакирҗанов сөйләвенчә, җирлеккә ике авыл керә, аларда 475 кеше яши. Мортаза авылында татарлар гомер итсә, Кырым-Сарай халкының күпчелеге – урыслар. Кеше саны буенча зур булмаган авылның мәктәбе дә, клубы да, балалар бакчасы да, чиркәве дә, инвалидлар өчен интернаты да, паркы да, янгын сүндерү депосы, ФАП, полиция участогы да бар. Һәйкәлен дә, якташлары – Советлар Союзы Герое Михаил Панарин бюстын да ясап куйганнар.

– Бәйгедә отуыбызның сере – әлеге биналарның барысына да куар-кодлар урнаштыруыбыз, – дип аңлатты Дамир Шакирҗанов. – Хәзер һәр җирдә цифрлаштыру турында сөйләп торалар, безнең дә моннан читтә каласыбыз килмәде. Әлеге номинациядә Татарстаннан бер безнең җирлек кенә катнашуы тагын да зуррак горурлык хисләре уята.

Куар-кодларны телефондагы махсус кушымта аша ачып, объектларның төзелү тарихын, елын, мәйданын, кыскасы, барлык мәгълүматны алырга мөмкин. Авылга керү юлындагы зур элмә тактага да урнаштырганнар куар-кодны. Анысыннан авылның тулы тарихын белергә мөмкин икән.

Шулай итеп, авыл җирлеге «Иң яхшы муниципаль практика» конкурсының «Цифрлы технологияләр һәм платформалы карарлар кертү юлы белән модернизацияләү («акыллы шәһәр»)» номинациясендә җиңеп чыккан. Өстәвенә, Татарстанда «Иң төзекләндерелгән җирлек» бәйгесендә өченче урын алып, 198 мең сум акча алуга ирешкәннәр.

– Бәйгедә катнашып, җирлек өчен шуның кадәрле акча алу – зур уңыш дип саныйм. Авылда яшәүчеләрнең тормыш шартларын яхшыртуның бер чарасы бу. Берничә җирдә күзәтү камералары урнаштырылган иде, акчаның бер өлешен өстәмә камералар куюга тотарбыз, дип торабыз. Мөмкин булган урыннарга андый җиһазлар урнаштырып чыксак, урлашу, тәртипсезләнү очраклары да булмас иде. Районга барып йөрмәс өчен, электрон терминаллар кую уе да бар. Моннан тыш, куелган куар-кодларны да яхшылап карап, яңгыр-карда бозылмаслык итеп эшләтәсе иде. Дөресен әйткәндә, бу җиңү һич көтелмәгәндә булды. Шуңа күрә әлегә акчаны нәрсә өчен тотасын кистереп кенә әйтә дә алмыйбыз. Ләкин ул, һичшиксез, үз урынын табар.

Шунысы мөһим: әлеге акчаны авылны цифрлаштыруга гына түгел, ә төзекләндерүгә дә тота алачаклар. Бу исә авыл халкының тормышын яхшыртуның тагын бер чарасы булып тора.

Аңлатып китик. «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия кече шәһәрләр конкурсын 2018 елдан бирле оештырып киләләр. Биш ел эчендә республикадагы җирлекләр 38 тапкыр 2,5 млрд сум федераль грантка ия булган. Узган ел әлеге дәрәҗәле бәйгедә ике җирлек җиңү яулаган. Аларның икенчесе – Алексеевск шәһәре. Беренче номинациядән аермалы буларак, биредә территориаль иҗтимагый үзидарә советларының халык белән тыгыз элемтәдә булуларына басым ясалган.

– Әлеге бәйгедә җиңү җиңел булмады, – диде Алексеевск шәһәре башлыгы урынбасары Валентина Увакина. – Аның беренче этабы 2021 елда узган иде. Без ул чагында Россия буенча өченче урынга лаек булдык. Әлеге талпыныш үз көчебезгә ышанырга сәбәп булды, барлык җитешсезлекләрне карап чыгып, территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең эшен тагын да камилләштердек. Шулай итеп, без узган ел республикада – беренче, Россиядә өченче урынга чыгып, 27 млн сум акча оттык. Бу – безнең өчен бик күп акча һәм, әлбәттә инде, зур мөмкинлекләр.

Валентина Увакина әйтүенчә, акчаның бер өлешен җәяүлеләр өчен юллар салуга, икенчесен яр буен төзекләндерүгә тотмакчы булалар. Бүген Алексеевск шәһәрендә 11 мең 700 кеше яши һәм өч территориаль иҗтимагый совет үзидарәсе эшли.

– Алар һәрдаим халык белән тыгыз элемтәдә эшли. Теләсә нинди проект шәһәрдә яшәүчеләр белән бергә уртага салып хәл ителә. Бу аларга төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге проблемаларны вакытында ачыкларга һәм хәл итәргә ярдәм итә. Алар халык белән төрле бәйгеләр («Иң яхшы ишегалды», «Иң яхшы клумба», «Иң актив кеше») уздырды, шулай ук экология, спорт чараларына да зур игътибар бирелде. Моннан тыш, территориаль иҗтимагый советлар «Безнең ишегалды» программасында да актив катнаша. Узган ел биш ишегалды төзекләндерелде, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УРАМЫҢНАН БАЛА УЗМАСА...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вазгыять

Сабый тумаса, бәла туа. Соңгы вакытта редакциягә авыллардагы бакчаларны кыскартуга бәйле хәбәрләр килеп ирешеп тора. Алар арасында Лаеш, Яшел Үзән районнарына кагылышлысы да бар. Әлеге имеш-мимешләр дөреслеккә туры киләме? Татар бакчаларының язмышы ничек хәл ителәчәк?

Пәрәү бакчасы ябыламы?

«Пәрәү авылындагы татар балалар бакчасын ябарга җыеналар. Анда 18 сабый йөри. Тәрбияче өчен акча юк, имеш. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы нәрсә карый?» Социаль челтәрдә таралган хәбәргә без дә битараф кала алмадык. Бакчаның язмышы турында кызыксынып, Лаеш районының мәгариф бүлеге башлыгы Лия Хөсәенова белән элемтәгә кердек.

– Пәрәү бакчасында 21 бала саналса да, күп дигәндә 11 бала йөрде. Бүген балалар бакчасына мөдир һәм тәрбияче кирәк. 9 гыйнварда мөдир һәм пешекче эштән китте. Шул сәбәпле, балаларны кабул итүче калмады. Шуннан соң әти-әниләр җыелышы үткәрдек. Аларга сабыйларын вакытлыча Державин бакчасына йөртеп торырга киңәш иттек. Әти-әниләр каршы килмәде, – дип аңлатты Лия Хөсәенова.

Бу бакчадагы тәрбияче, мөдир, пешекчеләр ни сәбәпле эштән киткән соң? Лия Хөсәенова белдергәнчә, хезмәт хакы – төп сәбәпләрнең берсе. Категориясе һәм стажы булмаган белгечнең хезмәт хакы минималь хезмәт хакы күләменә тиң.

Лаеш районы хакимияте Пәрәү бакчасын саклап калган. Тик әле штатта ни мөдир, ни тәрбияче юк икән. Пешекче дә, кече тәрбияче дә вакытлыча гына килгән. Мөдир вазыйфасын Пәрәү мәктәбе директоры башкара. Хәзерге вакытта өч бала Державин бакчасына йөри, калганнары – Пәрәү балалар бакчасына. Кадрлар булуга алар кире кайтачак.

Җиде сабыйга – җиде белгеч

Яшел Үзәннең Ачасыр, Күгеш, Мулла Иле авылларындагы бакчаларның да хәлен белештек.

Күгеш бакчасы мөдире Нурания Садриева әйтүенчә, бакча белән мәктәп кушылганга – 11 ел. Бер түбә астында булса да, алар икесе ике оешма булып санала. Анда балалар өч авылдан килә. 7 балага – 7 белгеч. Ике каравылчы, пешекче, тәрбияче, музыка белгече, кер юучы. Күбесе чирек ставкада эшли икән.

– Узган ел бакчага 15 бала йөрде. Алтысы 1 нче сыйныфка киткәч, сабыйлар азайган. Тагын ике бала өстәлсә, тугыз булачак. Туучылар башка күренми. Элек күрше-тирә авыллар белән чагыштырганда, иң күп сабый бездә иде. Авылда яшьләр калмый, үсеш юк. Мәктәпнең дә, бакчаның да проблемасы шул, – диде Нурания Садриева. – Яшем 63тә бит инде. Үземнең дә эштән китәргә исәп бар, оныклар янында күбрәк буласым килә.

Олы Ачасыр бакчасы мөдире Миләүшә Төхвәтуллина белән дә сөйләштек. Бакча авыл советы, медпункт, почта белән бер бинада урнашкан, мәктәп – аерым. Әлегә бакчаны кыскарту турында сүз юк. Миләүшә Төхвәтуллина, өч бала булса да, бакчаны саклап торалар дип, район мәгариф бүлегенә рәхмәтен белдерде.

– Бала булмагач, мәктәп, бакча бетә. Аннан авыл таркала. Авыл картайды, яшьләр юк. Янәшәбездән тимер юл үтү дә халыкны шәһәргә якынайта. Фермерлар да юк. Сабыйлар аз туа. Бөтен тирә-якта шундый хәл. Әти-әниләрнең балаларын түгәрәккә, репетиторга йөртәсе килә. Шуңа күрә шәһәргә китү ягын карыйлар. Авылда ферма бар, тик анда барып эшлиселәре килми. Безнең авылдан гына бер ел эчендә 15ләп яшь кеше чыгып китте. Шуларны калдырып була иде бит. Бала беттеме, авылда сукмак бетә. Олы кеше урамга чыкмый ул. Киләчәк – балалар кулында. Синең урамыңнан бала атлап китмәсен әле, бик кызганыч ул, – ди Миләүшә Төхвәтуллина.

Яшел Үзән мәгариф бүлеге башлыгы Рәйсә Афанасьева бакчаларны кыскарту-кыскартмау мәсьәләсенә ачыклык кертте.

– Бер бала булса да, бакчаны сакларга тырышабыз. Ачасыр, Мулла Иле, Күгеш авылларындагы бакчаларны кыскартырга җыенмыйбыз, – диде ул.

Бакчасыз калган Дөм-Дөм

Узган ел Алабуга районының Татар Дөм-Дөме авылында балалар бакчасы ябылган. Эш булмагач, авылда укытучы булып эшләгән ирле-хатынлы Хәмидуллиннар да алты ел элек шәһәргә күченгән. Моңа кадәр күрше авылга йөреп укытканнар, тик юл йөрүнең – үз газабы. Авылда 150ләп кеше яши.

– Эш булса, без авылдан китәсе түгел идек. Нигезебезне онытмыйбыз, авылга кайтып йөрибез анысы. 2005 елда ике катлы мәктәпне башлангыч мәктәпкә калдырдылар. Аннан анысы да бикләнде. Күрше Шүрнәк авылына йөреп укыттык, тик юл йөрү – үзе бер газап, – ди 4 бала анасы Айгөл Хәмидуллина. – Узган ел бакча бетерелде. Анда нибары бер генә бала йөргән. Ул гаилә дә авылдан күченеп киткән. Хәзер 4–5 бала бар, тик алар өйдә тәрбияләнә. Бакчага йөргән өчен түләргә кирәк бит. Бәлкем, шуңа да йөртәселәре килмәгәндер, белмим. Безнең балага – 5 яшь. Авылда яшәсәк, аңа бакча булмый иде инде. Быел медпункт та эшләми. Кеше, мөмкинлекләр эзләп, шәһәргә күченә.

Республикада күпме бакча кыскартылуы турында мәгълүмат юк. Ә тәрбиячеләр кытлыгы Казанда да бар. «Башкалада 6973 педагогик хезмәткәр эшли, шуларның 4603е – тәрбиячеләр. Шул ук вакытта 422 белгечкә ихтыяҗ бар», – дип белдерделәр Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәгендә.

– Район һәм шәһәрләрдә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына белгечләрне җәлеп итү буенча эш алып барыла. Вакантлы урыннар турында мәшгульлек үзәкләренә гаризалар тапшырыла. Буш урыннар турында мәгълүмат бакчаларның сайтында урнаштырыла, мәгариф бүлекләренә бирелә. Шулай ук белдерүләр «HeadHunter» һәм «Авито» социаль челтәрләре сәхифәләрендә бастырыла. Ел саен мөдирләр педагогика көллиятләрен тәмамлаучы белгечләрне үз бакчаларына җәлеп итү эшендә катнаша. Мәсәлән, Лаеш районында «2022–2025 елларда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына тәрбиячеләрне җәлеп итү һәм беркетү буенча» программа кабул ителде. Анда яшь белгечкә бер мәртәбә 180 мең сум түләү каралган, – диделәр министрлыкта.

Сәрия МИФТАХОВА

САН

Республикада татар телендә эшләүче **744** мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бар. Шулай ук **653** бакчада **1136** татар төркеме эшли.

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

«ВТ» – 105 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

Сафа Вафа улы Борһанов

1928–1930 ЕЛЛАРДА БАШ МӨХӘРРИР БУЛЫП ЭШЛИ

Сафа Борһан 1936 елның 30 декабрендә «Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше буенча «солтангалиевчелек»тә гаепләнеп кулга алына. Казан төрмәләрендә ярты елдан артык утырганнан соң, 1937 елның 3 августында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе үзенең күчмә сессиясендә әдипне башка бик күп тоткыннар белән бергә үлем җәзасына хөкем итә. Карар шул ук көнне – 1937 елның 3 августында җиренә җиткерелә. Кабере билгесез. 1957 елда аклана.

Әдип 1899 елның декабрендә Верхотур өязе, Пермь губернасында туа (Уралдагы Серебряный приискасында шахтер гаиләсендә туган дигән мәгълүматлар да бар).

1921–1924 елларда Мәскәүдә Сталин исемендәге Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик университетында укый. Аны тәмамлагач, 1926 елга кадәр РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитетында матбугат бүлеге мөдире булып эшли. Шул ук вакытта «Яңа авыл», «Яшь юксыл», «Башкортстан» газеталары белән хезмәттәшлек итә.

1926 елда Сафа Борһан Казанга килә һәм Татарстан дәүләт нәшриятының баш мөхәррире итеп билгеләнә. 1928–1930 елларда ул – «Кызыл Татарстан» газетасының баш мөхәррире, аннан 1935 елга кадәр «Красная Татария» газетасында баш мөхәррир урынбасары, бүлек мөдире, Казан авиация заводының күптиражлы газетасы мөхәррире булып эшли. Шул ук вакытта мәкаләләре «Безнең юл», «Җитәкче», «Тамашачы», «Фән һәм дин», «Яңалиф» журналларында басыла. Ә 1934 елдан «Известия» (Мәскәү) газетасының Татарстан буенча махсус хәбәрчесе булып эшли.

Сафа Борһан үз чорының матбугат дөньясында публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, очерклары, театр сәнгате турындагы рецензияләре белән таныла. 1928 елда «Үткәндәгеләр» дигән озын хикәясе һәм «Бозлар арасында» (1929) исемле очеркы аерым китап булып басылып чыга. Аның техникумнар өчен татар әдәбияты буенча төзегән хрестоматия-дәреслек китабы, дини йолаларга, диннәр тарихына багышланган «Ураза, корбан, сәдакалар», «Алла исеме белән» дигән публицистик хезмәтләре берничәшәр басмада дөнья күрәләр.

Исхак Усман улы Еникеев

1930–1931, 1937 ЕЛЛАРДА БАШ МӨХӘРРИР БУЛЫП ЭШЛИ

Исхак Еникеев 1900 елда Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында туа. 1920 елдан ВКП(б) әгъзасы. 1930–1931, 1937 елларда «Кызыл Татарстан» газетасының баш мөхәррире булып эшли. Ике кыз үстерә. 1937 елның 30 июнендә кулга алына. СССР Югары судының Хәрби коллегиясе карары белән «пантюркистик милләтчел оешмада торуы сәбәпле» берничә статья буенча хөкем ителә. Мал-мөлкәте конфискацияләнә. 1938 елның 9 маенда атып үтерелә. Казанның Архангел зиратында җирләнә. 1957 елда аклана.

Гаяз Гобәйдулла улы Ризванов

1932–1937 ЕЛЛАРДА БАШ МӨХӘРРИР БУЛЫП ЭШЛИ

Ул 1937 елның 4 апрелендә «милләтчел террорчылык оешмасындагы эшчәнлеге һәм Владимир Ленин, Карл Маркс әсәрләрен мыскыллауга юл куйганы өчен» кулга алына. 10 елга иректән мәхрүм ителә. Владимир шәһәрендә төрмәдә үлә. 1957 елда аклана.

Гаяз Ризванов 1904 елда элеккеге Нократ губернасы Сарапул өязе Исәнбай авылында (бүгенге Әгерҗе районы) туа.1921–1922 елларда Төмән шәһәрендәге педагогия техникумында укый. 1922 елда Казан совет партия мәктәбендә белем алуын дәвам иттерә, 1925 елда Татар коммунистик университетын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшкә урнаша. 1929–1930 елларда Казан университетының юридик факультетында декан була. Аннан Татар коммунистик университетына проректор булып кайта. Газета-журналларда ТАССРның мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси проблемалары буенча бик күп статьялар бастыра. 1932–1934 елларда ВКП(б) өлкә комитеты һәм Казан шәһәр комитеты пленумнарының әгъзасы була.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Арча

Соклану



АЛТЫ ШАТЛЫК

Кайвакыт матбугат карап утырганда, таныш исемнәргә һәм таныш йөзләргә юлыгасың да сөенәсең. Синең белән бер юлдан йөргән, аралашкан авылдашыңның, танышыңның уңышлары йөрәккә май булып ята, шатландыра. Күңелдә «Безнеке бит бу!» дигән татлы хис уяна.

«Ялкын» журналының 2021 елгы июль санын ачкач, минем күңелдә, мәсәлән, нәкъ шундый тойгы кузгалды. Журналның «Шәхес» дигән рубрикасында Ралинә Галәветдинова – авылдашларым Фәүзия һәм Рәдис Галәветдиновларның кызы, 2021 елда әле унсигез яшен генә тутырган үсмер турында күләмле язма урын алган. Унсигез яшьтә шәхес булу өчен, үзеңнең остаханәң белән уртаклашу өчен, байтак тырышырга кирәк. Белә идем мин Ралинәнең дизайнерлыкка укуын. Бу юнәлештә сәләте зурлыгын да аңлый идем, чөнки гаилә бик таныш, көндәлек аралашып яшәгән кешеләр.

Журнал битендәге Ралинәгә карыйм да, күз алдымда язмышлар калейдоскобы әйләнә. Менә аның әтисе Рәдис – балалар бакчасына йөргән сабый, аннан соң мәктәптә бик яхшы билгеләргә генә укып, медаль белән тәмамлаган үсмер, тагын аз гына вакыт үтүгә, ул инде – авылның имамы… Әле яңа гына күрше авыл кызы Фәүзия белән гаилә корганнар иде, хәзер инде әнә кызлары: «Кечкенәдән үк тегү эшенә тартыла идем. 8–9 яшьләрдә «Барби» курчакларына киемнәр тегә башладым. Әкренләп бу эш миңа рәхәтлек китерә башлады. Дизайнер һөнәре минем кечкенә генә хыялыма әйләнде», – дип, «Ялкын»га интервью бирә.

Ралинәнең талантына һәм, Аллаһ теләсә, киләчәктәге уңышларына шикләнмим мин, чөнки, бердән, бу нәселгә тәкъдирләрнең Хуҗасы сәләтләрне өеп биргән, икенчедән, бу – күпбалалы гаилә. Күпбалалы гаиләдә балалар гадәттә тырыш була. Әтиәнинең шәхси үрнәге таләп ителә, әлбәттә. Шәхси үрнәк мәсьәләсе исә болайрак: авылның өлкән имамы авырый башлап, аның урынына кеше таба алмагач (авылда тиешле таләпләргә җавап бирердәй кеше булмау гаҗәп түгел), бик нык кыстап, үгетләп, әлеге вазыйфага утыз бер яшьлек Рәдисне тәкъдим иттек. Имамның нәрсә хисабына яшәячәге турында сүз кузгалткач, ул, өздереп, бер генә җөмлә әйтте: «Минем кулым эш белә». Чынлап та шулай иде. Рәдис балачактан сурәтләрне коеп кына куя, исәп-хисапка бик җитез (югары белемле математик), кулында эш кораллары уйнап кына тора. Ничә йортны нигезеннән алып түбәсенә кадәр күтәреп чыгуын үзе дә белми торгандыр. Бу юллар авторы гаиләсе өчен генә дә ике йорт шуның куллары белән күтәрелде. Нәрсәдер төзисе булса, аның проектын, сметасын, материалларын, мәсәлән, әле дә шуннан исәпләтәм. Һәм эшне соңгы ноктасына кадәр шуңа тапшырам да. Хәтерлим әле: Ташкичү мәктәбен ремонтлап, заманча бинага әверелдергәндә, имам төзегән һәм җитәкчелек иткән бригада зур эш башкарды, нәкъ шул бриганың эше район газетасында аерым мактап искә алынды. Үткән көздә җилгә, яңгырга, карга карамыйча, район администрациясе бинасының түбәсен эшләп чыктылар.

Галәветдиновлар гаиләсе күп итеп терлек асрый, пай җирләрен алып эшкәртә. Рәдис күп вакыт төзелеш эшләре белән читтә йөргәнгә, шәхси хуҗалыкны тәртипле итеп алып бару Фәүзия һәм балалар җилкәсенә төшә. Мәктәп ашханәсендә эшләүче Фәүзия барысына да өлгерә. Боларны ник язасың, диярсез. Үткән җәй Ташкичүгә килгәч, Риман абый Гыйлемханов миннән: «Авыл кешесе нәрсә хисабына яши?» – дип сораган иде. Карагыз: алты балалы гаилә (ике кечкенә малай әле бакчага йөриләр) кредитсыз-нисез менә дигән итеп каралты-кураны төзеп, трактор-машина алып, беркемгә дә ялынмыйча, авылда тормыш алып бара. Чөнки кулларын тик тотмый һәм Аллаһы Тәгалә биргән сәләтләрен киң файдалана. Әти белән әнинең сәләтләре дә, тырышлыгы да балаларга күчә. Беренчесе генетикага бәйле һәм безнең катнашыбыздан башка хәл ителсә, эшлеклелек һәм тырышлык – тәрбия һәм шәхси үрнәк нәтиҗәсе. Менә шулар талант белән кушылгач, күпбалалы гаиләдә дә пөхтәлек һәм чисталык, муллык күрәбез.

Каннан, тумыштан килә торган талант мәсьәләсе дә бик кызыклы бит ул. Мин махсус балаларның портфолиоларын сорап алып карадым. Элекке укытучы инстинкты уянды, берәмләп, җентекләп, барысын да өйрәнеп, тикшереп чыктым. Дипломнар һәм грамоталар саны таң калдырырлык. Менә карагыз: Фирдинә – гаиләдәге икенче кыз – мәктәптәге беренче бүләкләрен беренче сыйныфта укыганда ук Россия күләмендәге математика буенча интернет-олимпиадада икенче дәрәҗәдәге диплом, район күләмендәге «Яшь рәссам» конкурсында беренче урын грамотасы рәвешендә алган. Соңрак сәнгатьле уку һәм үзешчән сәнгать өлкәсендәге уңышлар (болары, мөгаен, Фәүзия аша тапшырылган геннардандыр) өстәлгән. Гаиләдәге иң өлкән бала Рәмиснең дә уңышлары – математика, рәсем сәнгате һәм спорт өлкәсендә. Әйтик, үсмерләр арасында көрәш буенча район беренчелеге – аныкы. Чаңгы ярышында җиңүләр – аныкы. Армия сафларында хезмәт иткәндә алган грамотасына: «За высокие показатели в боевой подготовке, примерную воинскую дисциплину, отличие и разумную инициативу…» – дигән сүзләр язылган. Әле икенче сыйныфта гына укучы Ихсанның 6 яшьтә «Салават күпере» журналында рәсеме басылып чыккан. Хәсән белән Хөсәенгә сәләтләрен күрсәтергә әлегә иртәрәк, алар бакчага йөри.

Рәдиснең үзенең соңгы елларда алган диплом һәм грамоталары гына да калын бер портфолиолык. Имамнар бәйгесендә ел саен я беренче, я призлы урын. Болар барысы да – армый-талмый эшләү, гыйлем алу нәтиҗәсе. Балаларның әти-әни үрнәгендә җиңүләр яулавы гаҗәп түгел.

Без шатлыкта да, кайгыда да имамга барабыз бит. Бала туса да, гаилә корылса да, җеназа булса да… Күп нәрсәне ничектер имам эшләргә, үтәргә тиеш, дип уйларга гадәтләнгәнбез. Имамлык хезмәтенең вакыт таләп итүе, мәшәкать соравы хакында уйлап та карамыйбыз. Мөселманнар лидерының кешеләргә сөйләп йөрми торган игелекле эшләре дә була, аларын, аңлашыла инде, без дә сөйләп тормыйбыз.

2022 елда Татарстанда алты балалы бары тик 268 генә гаилә булган икән. Арча районында – җидәү. Кешеләр бала тәрбияләү мәшәкатеннән баш тартып, ил демографик кризиска баткан да, үрнәк гаиләдә «сөбханаллаһ», «бәрәкаллаһ» дип әйтерлек балалар үстерү – зур батырлык. Галәветдиновлар гаиләсенә алты бала гел алты шатлык булсын, дигән теләктә калабыз.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

«10 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (Чаллы шәһәре) **Бодрова** Ирина Аркадьевнага, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Лениногорск шәһәренең 6 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Никифорова** Ирина Александровнага, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең квалификация күтәрү үзәге башлыгы **Салихова** Лилия Фәннур кызына, «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең 8 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Сафина** Роза Идрис кызына, хезмәт ветераны **Филиппова** Клара Мәрдән кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ТУГАН РЕСТОРАН-2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үсеш буенча директоры **Абдрахманов** Радик Мөхәрләм улына, «Үткәнгә сәяхәт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры **Кокурин** Алексей Евгеньевичка, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең график модельләштерү кафедрасы профессоры **Айдаров** Равил Сәйяр улына, «Гамәли археология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Истомин** Константин Эдуардовичка, «Елена Шилованың архитектура-реставрация компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шилова** Елена Андреевнага, «ТАСКШЕРИНГ РУС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Губаев** Радик Риф улына, «СМАРТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Идиятов** Илсур Марс улына, «Ритуал» җирләү йолаларын оештыру хезмәте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Мостафин** Радик Рамил улына, «Яр буе сәүдә йорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Салихов** Илнар Рамил улына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хезмәткәрләре: икътисад бүлеге башлыгы **Гайзетдинова** Лилия Рафаэль кызына, җир ресурслары идарәсенең җирле үзидарә органнары белән җир мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне оештыру бүлеге башлыгы **Гафарова** Ольга Георгиевнага, бәяләү бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Миниханова** Эльвира Фидаил кызына, милек идарәсенең торак күчемсез милек, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы **Хәсәнова** Ирина Александровнага, милек идарәсенең дәүләт милкеннән файдалану бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Шкаликова** Лариса Александровнага, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең янгын сүндерү-коткару отряды 15 янгын сүндерү-коткару часте 55 бүлекчәсе командиры **Гафаров** Ринат Мулланур улына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең янгын сүндерү-коткару отряды 11 янгын сүндерү-коткару часте 88 бүлекчәсе командиры **Хаджаев** Илдар Илшат улына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы **Вәлиев** Азат Рөстәм улына, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары **Музалевская** Алеся Ислам кызына, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе хезмәткәрләре: юридик яктан тәэмин итү бүлеге баш белгече-эксперты **Гыйматдинова** Диларә Ибраһим кызына, идарә җитәкчесе ярдәмчесе **Мөхәммәдиева** Регина Радик кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Хайваннар дөньясы

Эзеннән табалар

Гыйнварның 15еннән республикадагы кыргый хайваннарның санын ала башладылар. Бу эш март уртасына кадәр дәвам итәчәк. Хайваннарны кышкы исәпкә алу барышында белгечләр 14 төр җәнлекне һәм 4 төр кошны санаячак.

Татарстан Биоресурслар буенча дәүләт комитетының хайваннарны һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе җитәкчесе Ринат Чиспияков аңлатуынча, хайваннарны кышкы маршрут буенча, ягъни эзенә карап, һавадан күзәтеп, туклану урынына җыеп, артларыннан барып исәпкә алалар.

Кышкы маршрут алымы поши, кыр кәҗәсе, кабан, боланнарны, селәүсен, бүре, төлке, кеш, сусар, сасы көзән, ас, себер көзәне, тиен, куян, шулай ук бoҗыр, көртлек, суер, кыр тавыгы һәм фазаннарны санаганда кулланыла. Поши һәм себер кыр кәҗәләрен һавадан күзәтеп тә саныйлар. Туклану урыннарында исәпкә алуның үзенчәлеге – тояклы хайваннарны алдан әзерләнгән ашату урыннарында санау. Бу ысул белән кабан дуңгызы, болан, кыр кәҗәләре саны билгеләнә. Артларыннан барып исәпкә алу ысулы исә Татарстанда кулланылмый.

– Без җәнлекләрне эзләре буенча, һавадан күзәтеп һәм туклану урыннарында санаячакбыз. Хайваннарны чаңгыларда, кар машиналарында йөреп, алдан әзерләнгән маршрут буенча эзләргә карап барлыйбыз. Исәпкә алып, кайсы төр җәнлекне арттырырга, кайсын киметергә кирәклеген ачыклыйбыз. Саннарга карап, ауга рөхсәт бирәбез. Кимегәннәрен исә Кызыл китапка да кертәбез, – ди Ринат Чиспияков.

Җәнлекләрне исәпкә алу өчен, башта кар яву, аннан соң аның кимендә 20 сәгатькә туктап торуы кирәк. Буран һәм җил булса, эзләрне табып булмаячак. Балтач районында да хәзер эшнең кызу чагы. Аучылар хайван эзен саный. Күп еллар шушы эш белән шөгыльләнүче Ринат Шәйхетдинов иртәдән алып кичкә кадәр урман-басуларда йөри.

– Кар явып киткәннән соң эз төшеп калсын өчен, бераз көтәргә кирәк. Беренче көнне без хайваннарның йөргән юлы буйлап узабыз. Уңнан сулга, сулдан уңга йөрибез. Ничә куян узган, күпме төлке эзе бар – барысын да исәпкә алабыз. Безнең якларда куян белән төлке, поши, кабаннар күп, көртлекләр аз, – ди Ринат. – Икенче көнне исә тагын шул маршрут белән чыгып китәбез. Бу юлы инде саннарны кәгазьгә үк теркәп куябыз. Аннары без ул саннарны Татарстан Биоресурслар буенча дәүләт комитетына юллыйбыз. Татарстанның табигый байлыгы әнә шулай катлаулы юллар узып исәпләнә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАНДА – КЫРГЫЙ ТАБИГАТЬ



	2021 ел	2022 ел
Поши	10500	13598
Кабан	1400	1211
Кыр кәҗәсе	10200	12609
Куян (соры)	28100	28349
Куян (ак)	7500	8804
Төлке	7000	6798
Сусар	2500	2471
Көртлек	73300	140435
Суер	2800	2946
Кыр тавыгы	151800	225166

ҮРНӘК ҺӘМ ГЫЙБРӘТ

КАЗАНДА МАХСУС ОЛИМПИАДАНЫҢ БЕРДӘМ УЕННАРЫ БАШЛАНДЫ

Спорт кына түгел бу

Монда тизрәк, көчлерәк, җитезрәк булырга дигән максат юк. «Иң мөһиме – катнашу» дигән кагыйдә күбрәк тә туры килә бугай әле. Катнашучылар арасындагы мөнәсәбәт тә көндәшлеккә түгел, дуслыкка корылган. Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннары турында сүз. Татарстан башкаласында аның ачылыш тантанасы узды. Бүгеннән исә катнашучыларны ярышлар көтә. Уеннарның әһәмияте нидә? Спортчылар аннан ни көтә? Мәгънәле ачылышны «ВТ» хәбәрчесе дә карап кайтты.

tatarstan.ru

Алар – җиңүче

Махсус Олимпиаданың гади генә ярыш түгеллеген язган идек инде. Ул акыл ягыннан тайпылышлары булган спортчылар өчен үткәрелә. Паралимпия Уеннары белән бутарга ашыкмагыз: монысында физик көч, физик мөмкинлекләр турында сүз бармый. Ярышлар да медаль-бүләк өчен үткәрелми. Иң элек сәламәтлеге ягыннан чикләнелгәннәрнең мөмкинлекләре чиксез икәнен күрсәтү, аларга җәмгыятьтә үз урыннарын табарга булышу, сәләтләрен сынап карау өчен мохит булдыру максаты күздә тотыла.

Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов әйтүенчә, бик күпләргә әлеге ярышларда катнашучылардан үрнәк алырга була. Сүз уңаеннан, Татарстаннан анда 156 кеше катнаша. Шуларның 95е – спортчылар.

– Мамадыш, Саба, Минзәлә, Яшел Үзән кебек районнардан, Казан, Чаллы шәһәрләреннән катнашучылар бар. Алар ярышларга әзер, – диде Хәлил Шәйхетдинов «ВТ»га. – Мин ышанам: бу ярышлар спортчыларга үз мөмкинлекләрен тулысынча күрсәтергә, киләчәктә исә мондый юнәлешләргә игътибарны арттырырга ярдәм итәчәк. Уеннарда катнашмаган районнар да бар. Аларга да киләчәктә уйланырга булыр. Бу Уеннарга әзерләнгәндә, халыкның фикере үзгәрүен сиздек. Ул бит әле спорт ярышлары гына түгел, үзенчәлекле спортчылар белән шөгыльләнгән кешеләргә игътибарны арттыру да.

Министр урынбасары әйтүенчә, ярышлар гыйбрәт өчен дә оештырыла, дияргә мөмкин. «Беркайчан да иренмәскә, ялкауланмаска кирәк. Нинди генә халәттә булсаң да, үзең теләгән спорт төре белән шөгыльләнеп, сәламәтлекне ныгытырга мөмкин. Мин бу катнашучыларның ата-аналарына, тренерларына рәхмәтле. Алар – безнең өчен берникадәр дәрәҗәдә үрнәк тә, гыйбрәт тә. Сау-сәламәт булып та, күпләребез чаңгы юлларына басмыйбыз, йөзү бассейннарына йөрмибез. Спортка вакыт тапмыйбыз. Иренәбез! Ә алар алга барырга, тукталып калмаска икәнне үз үрнәкләрендә күрсәтә», – дигән фикердә Хәлил Шәйхетдинов.

Катнашучыларның да өметләре зурдан. Борчылу да бар, әлбәттә. Әмма яннарында тәҗрибәле остазлары, ата-аналары булгач, анысы онытыла.

Чаңгы ярышында Татарстан командасыннан катнашучы Снежанна Баранова Уеннарны зарыгып көтеп алган. Шактый әзерләнгән дә.

– Монда бик күп дусларны очраттым, башка шәһәрләрдән яңа дуслар таптым, шуңа сөенәм әле. Спорт белән бик дус мин. Үземне күрсәтергә, иң яхшысы булуымны исбат итәргә телим! – ди кыз.

Саба кызы Ләйсән Зарипованы да Татарстанда яхшы беләләр. Бердәм Уеннарга өстәл теннисы буенча ярышырга килгән. Янәшәсендә көч-дәрт биреп торырга әнисе Рәмзия ханым бар.

– Ләйсән җиденче елын өстәл теннисы белән шөгыльләнә. Бик күп җиңүләребез бар. Без – мондый ярышларның еш кунаклары, – ди ул. – Җиңәбез дип торабыз.

Уеннар – саннарда

- Ярышлар 26 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк.
- Катнашучылар 18 төрле дисциплинада көч сынашачак.
- Уеннарда Россиянең 59 субъектыннан һәм Белоруссиядән 2 меңнән артык спортчы катнаша.
- Ярышларда катнашучы иң өлкән спортчыга – 52 яшь. Ул Владимир өлкәсеннән килгән. Иң яшенә исә – 9 яшь. Ул Липецкидан.

Хәерле ярышлар булсын. Оештыручыларга зур рәхмәт. Бик күңелле. Мондый чаралар безнең өчен бик мөһим. Сер түгел, мөмкинлекләре чикле балалар күбрәк социаль яктан изоляциядә кала. Ә мондый спорт бәйрәмнәре шул күләгәдән чыгарга булыша, гаиләләргә көч бирә. Без бик мәгънәле тормышта яшибез. Ләйсән белән миңа да тик тору юк, спорт – минем дә дустым. Сәламәт кенә булсыннар, йөзләреннән елмаю китмәсен. Ләйсән – бик күпләргә җитеп бетмәгән мотивацияне таратучы да әле ул.

Санкт-Петербург шәһәреннән делегациядә 100дән артык кеше бар. Спортчылар нигездә өстәл теннисы, баскетбол, нәфис гимнастика кебек спорт төрләрендә көч сынашачак.

Тренер Татьяна Гурова укучысы Мария белән җиңү өчен түгел, ә уңай хис-кичерешләр өчен килгәннәр. Маша кыска чаңгыда йөгерүдә осталык күрсәтәчәк.

– Мин Машаны 90 нчы еллар башында балалар йортына педагог булып эшләргә килгәч күреп алдым да аның белән шөгыльләнә башладым. Бик актив ул. Башта нәфис гимнастика белән мавыктык. Аннан атта да йөрдек, чаңгы да шудык. Машаның җиңүләре дә күп. Безнең өчен спорт ул – тормыш, хәрәкәт. Шуңа да яшь, сәламәт килеш саклангaнбыздыр да. Күреп торасыз, Машага үз яшен әле дә биреп булмый бит (Мариягә – 41 яшь. – **Авт.**), – дип сөйләде Төньяк башкала кунаклары.

Сахалин утравыннан килгән Полина Амельчук Казанга ишарәләр теле белән рәхмәтен җиткерде.

– Мондый зур ярышның бер өлеше булуыма бик сөенәм. Барлык катнашучыларга да сәлам юллыйм. Казанга бик зур рәхмәт, – диде кыз.

Белоруссиядән Алеся Суворова баскетболны үз итә. Җиңүенә ышанычы да зурдан кызның. Аңа – 19 яшь. Спорт белән күптәннән дус икән инде.

– 2 сыйныфтан башлап баскетбол белән шөгыльләнәм. Бу – көчле рухлылар һәм чыдам кешеләр спорты. Ә мин нәкъ шундый! Баскетбол – команда белән эшләргә өйрәтә торган спорт төре дә әле, – диде ул. – Зур спорт ярышларына еш йөрим. Безнең республикада да андый чаралар еш уза. Гарәп Әмирлекләренә кадәр ярышырга барганым булды. Казандагы чараны исә түземсезлек белән көттем.

Президенттан хәер-фатиха

Рәсми ачылыш көнне, Татарстан данын яклаучы команда белән Президент Рөстәм Миңнеханов та очрашты. Ул аларга киңәшләрен бирде, уңышлар теләде. Катнашучылар да җавапсыз калмады – үз куллары белән ясаган күчтәнәчләре дә бар иде аларның. Әлбәттә, Президентка «җиңәчәкбез» дип тә вәгъдә иттеләр.

Ачылыш тантанасында катнашучыларга җылы сүзләр күп яңгырады.

Россия спорт министры Олег Матыцин билгеләп үткәнчә, иң мөһиме – катнашучыларга зур спорт гаиләсенең бер өлеше булуларын тоярлык мохит тудыру.

– Татарстан җирендәге бәйрәм безнең ачык булуыбызны, безнең чиксез мөмкинлекләребезне күрсәтәчәк. Бу вакыйгада Белоруссиядән һәм 59 төбәктән дусларыбыз катнашу бик мөһим. Безнең гаилә Россия белән генә чикләнми, бу хәрәкәтнең чикләре юк. Бу – ярыш кына түгел, ә Россиядә гуманистик кыйммәтләр системасын төзү дә, – диде ул. Министр сүзләренчә, мондый Уеннарны даими итү мөмкинлеге дә каралачак.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Уеннар – үзенчәлекле проект, анда катнашучылар да үзенчәлекле.

– Бу Уеннар безгә бер-беребезне аңларга ярдәм итә. Сезне барыгызны да тормышка мәхәббәт, алга бару омтылышы берләштерә. Татарстанда сез үзегезне уңайлы хис итәрсез дип ышанам, – диде үз чыгышында республика Президенты.

Махсус Олимпиаданың Россиядәге Президенты Ольга Слуцкер искәрткәнчә, Уеннар җәмгыятькә гуманизм кыйммәтләрен алып килә.

– Махсус Олимпиада һич кенә дә секундлар, рекордлар кую, медаль алу өчен түгел. Ул акыл ягыннан тайпылышлары булган кешеләргә тырышлыкларын, ихтыяр көчен сынау өчен, үз-үзләренә ышаныч арттыру өчен кирәк. Безнең хәрәкәт җәмгыятькә гуманизм кыйммәтләрен алып килү миссиясен үти, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

УЙНАТАЛАР ДА, КУРКЫТАЛАР ДА

Наркотикларга бәйлелек турындагы драма, куркыныч әкият һәм нәниләр өчен әлифба-спектакль. Кариев театрында берьюлы өч премьерага багышланган матбугат очрашуы узды. Спектакльләр нәрсә турында? Премьералардан ни көтәргә? Сүзебез шул турыда булыр.

«12 адым» (12+)

«Бу хакта без, гадәттә, сөйләшергә яратмыйбыз, йә куркабыз. Шулай да, тәвәккәлләп, сөйләшергә булдык». Бу юллар – «12 адым» спектакленең аннотациясеннән. Кариев театры 25–26 гыйнварда наркотикларның кеше тормышына һәм шәхесенә җимергеч йогынтысы турындагы документаль спектакль тәкъдим итәчәк. Иҗат төркеменә килгәндә, драманы – Булат Минкин, спектакль өчен музыканы Йосыф Бикчәнтәев иҗат иткән. Режиссеры – Әминә Миндияр.

– «12 адым» – социаль юнәлештәге спектакль. Әминәне чакырган вакытта, бурычны болайрак куйдык: спектакльдә беренче урында сәнгати яссылык түгел, ә документальлек, социаль эчтәлек булырга тиеш. Аны килеп караган үсмерләр наркотиклар белән бәйләнгән егет-кызларның язмышын, наркотикларга бәйлелекнең кая һәм нинди хәлгә илтәсен, бу проблемадан нинди чыгу юллары барлыгын күрәчәк, – диде беренче премьера турында театрның директоры Луиза Шарова.

Спектакль эчкечелек һәм наркотикларга бәйлелекне дәвалауга юнәлдерелгән «12 адым» программасына нигезләнгән.

«12 адым» программасын узган гасырның 30 нчы елларында үзе дә эчкечелектән тилмергән Билл Уилсон исемле кеше төзегән. Башта ул эчкечеләрне дәвалау өчен кулланылса, бераздан аның ярдәмендә наркоманнарны да дәвалый башлаганнар.

– Гадәттә, наркотиклар турындагы фильмнарны бик матур итеп, романтик рухта төшерәләр. Ә безнең спектакль тамашачыларда наркотикларга карата җирәнү уятыр дип өметләнәбез. Яшьләр бит наркотикларның начар икәнен белә, әмма ни өчен начар икәнен аңлап җиткермиләр. «12 адым» – калыплашкан фикерләрсез, хөкем итүләрсез ачыктан-ачык сөйләшү, – диде спектакльнең режиссеры.

«Гөлчәчәк» (12+)

«Кич белән, театрның иң соңгы хезмәткәре кайтып китеп, ишекләр бикләнгәч, монда куркыныч әкият башлана». Бу юллар – «Гөлчәчәк» хоррор-әкиятенең аннотациясеннән. Гади итеп әйткәндә, театрның яшь актеры Булат Гатауллин, үзен тәүге тапкыр режиссер буларак күрсәтеп, куркыныч әкият куячак. Дөрес, «Гөлчәчәк»не «Һөнәр» яшь режиссура фестивале кысасында күрсәттеләр инде. 9 февральдә аның зур премьерасы булачак.

– Бу спектакль белән тулы бер цикл башлап җибәрәсебез килә. Халык әкиятләре, милли шигърият, хатлар, мемуарларны балалар һәм үсмерләргә аңлаешлы формада җиткерә ала торган кыска гына спектакльләр, алар белән бергә фикер алышу яки лекция форматындагы очрашулар оештырырга телибез. Бу очрашуларны «Мәтрүшкә party» дип атадык, – диде Луиза Шарова.

Спектакльне театрның фойесында күрсәтәчәкләр.

– «Гөлчәчәк»не балалар да, үсмерләр дә, тәнкыйтьчеләр дә килеп карарга өлгерде. Һәммәсенә дә ошады. Балаларның эмоцияләре, реакцияләре бик кызык булды. Таң калып карады алар. Ә бу – иң мөһиме, – диде Убырлыны уйнаучы Алсу Шакирова.

«Әлифба: Хәрефләр дөньясында» (2+)

«Әлифба – дөньяны танып белә генә башлаган сабыйның аңына юл салучы ул». Бу юллар – «Әлифба: Хәрефләр дөньясында» спектакленең аннотациясеннән. Монысы инде – иң кечкенәләр өчен уен формасындагы спектакль. Режиссеры – Лилия Әхмәтҗанова.

Бераз гына «спойлер»: әлифбадагы хәрефләр, без татарча көннән-көн азрак сөйләшкәнгә үпкәләп, качып киткәннәр икән… Спектакльдә актерлар, балалар һәм аларның әти-әниләрне, шуларны табып алып, кире үз урыннарына кайтарачак. Бу хикмәтле хәрефләр дөньясын беренче булып күрергә теләүчеләрне 22 февральдә – спектакльнең премьерасында көтәләр.

– Бу спектакль татар мохите турында. Әлеге мохиткә балалар да «чума» алсын өчен, әлифбаны кулланырга булдык. Спектакль уен формасында барачак. Артистлар балалардан әлифбадагы һәр хәрефкә туры килә торган сүзләр сораячак. Кыскасы, нәни тамашачылар процессның эчендә «кайнаячак», – дип сөйләде спектакльнең режиссеры.

Спектакль өчен декорацияләрне күчмә форматта да эшләп булырлык итеп ясаганнар. Шуңа күрә киләчәктә аны балалар бакчаларына, мәктәпләргә дә алып барырга ниятлиләр.

vk.com/kariev_teatri

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 210

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+